# КАРАР

**“19 октябрь 2021 ел** **№ 1**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Түбән Мәтәскә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 02нче ноябрь 2020 ел, №1 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча эш төрен үзгәртү өлешендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Түбән Мәтәскә авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 19 октябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Түбән Мәтәскә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2020 елның 2 ноябрендәге 1 номерлы карарына «Түбән Мәтәскә авылында су башнясы урнаштыру» һәм «Түбән Мәтәскә авылында гамәлдәге скважинага капиталь ремонт ясау» эшләр төрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү белән килешәсезме?

« ӘЙЕ» “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 368 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 185 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 181 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 4кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Түбән Мәтәскә авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Түбән Мәтәскә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2020 елның 2 ноябрендәге 1 номерлы карарына «Түбән Мәтәскә авылында су башнясы урнаштыру» һәм «Түбән Мәтәскә авылында гамәлдәге скважинага капиталь ремонт ясау» эшләр төрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү белән килешәсезме?

ӘЙЕ» - “КАРШЫ“-

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Түбән Мәтәскә авылы, Тукай урамы, 2 йорт; адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Лутфуллин